МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.07.2017 г. Казань № 340-пр

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркем өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлардагы сәхифәләр турында белешмәләрне, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында**

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 20.2 статьясы, “Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 17.2 статьясы нигезендә б о е р ы к б и р ә м :

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре

министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркем өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлардагы сәхифәләр турында белешмәләрне, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерүнең теркәлгән Тәртибен расларга

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының _____ елның ______
340-пр номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркем өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлардагы сәхифәләр турында белешмәләрне, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү Тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркем өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлардагы сәхифәләр турында белешмәләрне, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү Тәртибе (алга таба – Тәртип) түбәндәгеләрне билгели:

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар (алга таба – гражданин) һәм Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәре) һәркем өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлардагы сәхифәләр турында белешмәләрне, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны (алга таба – Сайтлар турында мәгълүмат, «Интернет» челтәре) тапшыру кагыйдәләрен;

Сайтлар турында мәгълүматны кабул итү һәм эшкәртү тәртибен;

Сайтлар турында мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртәбиен

2. “Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында” 27 июль, 2006 ел, № 149-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, һәркем өчен ачык мәгълүмат төшенчәсе танышу чикләнелмәгән гомуммәгълүм белешмәләрне һәм башка мәгълүматларны аңлата. Шул ук вакытта мәгълүмат белән танышуда чикләүнең булмавы, урнаштырылган мәгълүматның, граждан хезмәткәре яки гражданин ризалыгыннан башка гына, чикләнмәгән затлар даирәсе тарафыннан тоткарлыксыз алыну һәм үзләре теләгенчә куллану мөмкинлеген күздә тота.

3. Граждан хезмәткәренең яки гражданинның шәхесен тәңгәлләштерү мөмкинлеге бирүче мәгълүматлар сыйфатында түбәндәге мәгълүматлар җыелмасы яки шул мәгълүматларның берсе булырга мөмкин: фамилиясе һәм исеме, фотосурәте, хезмәт итү урыны.

## II. Сайтлар турында мәгълүматны кабул итү һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турында белешмәләрне тапшыралар:

гражданин – Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенә (алга таба – гражданлык хезмәте) кергәндә – гражданлык хезмәтенә керү елына кадәрге өч календарь елы өчен;

граждан хезмәткәре – ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча – алдагы календарь елы өчен.

5. Сайтлар турында белешмәләр гражданнар һәм граждан хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән формада (алга таба – Форма) тапшырыла.

6. Граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында урнаштырылган очракта, барлык кешеләр өчен ачык мәгълүмат Формада чагылдырылмый.

7. Тутырылган Форма граждан хезмәткәре яки гражданин тарафыннан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры (алга таба – министр) боерыгы нигезендә Сайтлар турында мәгълүматлар эшкәртүгә җаваплы итеп билгеләнгән кадрлар бүлеге мөдиренә (алга таба – җаваплы зат) тапшырыла.

8. Җаваплы зат Форманы алган көнне Форманың тулы итеп тутырылу-тутырылмавын, “Интернет” челтәреннән файдаланып, анда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерә, шәхси имзасын куя, әлеге Тәртипнең Кушымтасы нигезендәге форма буенча журналга белешмәләр кертә.

9. Кайбер юллары тутырылмый калган Форма кабул итеп алынмый.

10. Гражданин тарафыннан тапшырылган Формада дөрес булмаган мәгълүматлар ачыкланган очракта, кадрлар бүлеге аңа граждан хезмәте

вазыйфасына билгеләүдән баш тарту турында кичекмәстән хәбәр итә.

11. Сайтлар турында белешмәләр җаваплы зат тарафыннан граждан хезмәткәрләренең “Татарстан Республикасында дәүләти гражданхезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы” дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси карточкаларына кертелә.

12. Граждан хезмәткәрләре һәм гражданнар тарафыннан тапшырылган формалар Татарстан Республикасы кадрлар бүлегендә биш ел дәвамында саклана, шуннан соң алар Министрлыкның “Министрлыкта персональ мәгълүматларны юкка чыгару буенча комиссия турында” 26.04.2016 № 210-по боерыгы белән расланган Министрлыкта персональ мәгълүматларны юкка чыгару Регламенты белән билгеләнгән тәртиптә юкка чыгарылырга тиеш.

## III. Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13. Граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшырылган Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү министр яки аның вазыйфаларын башкаручы зат боерыгы нигезендә тормышка ашырыла.

14. Түбәндәгеләр тарафыннан язмача рәвештә тапшырылган мәгълүмат тикшерүгә нигез булып тора:

хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары;

сәяси партияләрнең һәм закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булып тормаучы башка гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләрнең даими эшләүче җитәкче органнары;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы;

гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары.

15. Җаваплы зат, тикшерү үткәрү турында боерык чыкканнан соң ике эш көне эчендә, граждан хезмәткәренә үзенә карата Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча тикшерү башлануы турында язмача хәбәр итә.

16. Җаваплы зат граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын “Интернет” челтәрендә гражданлык хезмәткәре урнаштырган һәркем өчен ачык мәгълүматны эзләп табу һәм күрсәтелгән мәгълүматның электрон күчермәләрен (скриншотлар) булдыру юлы белән тикшерә

17. Граждан хезмәткәре тикшерү барышында һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча язмача рәвештә аңлатмалар бирергә, өстәмә материаллар тапшыруга хокуклы

18. Әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына теркәлә.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында тупланган мәгълүматлар министрга тикшерү үткәрү турында боерык басылып чыкканнан соң 10 эш көненнән дә артмаган срокта тапшырыла.

20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча министр 5 көн эчендә түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын куллануга нигезләрнең булмавы турында;

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

хокук бозу, җинаять, экстремистлык эшчәнлегендә катнашу билгеләре булганда, тикшерү материалларын тиешле компетенциядәге дәүләт органнарына җибәрү турында.

21. Җаваплы зат министр тарафыннан кабул ителгән карар турында ике эш көне эчендә үзенә карата тикшерү үткәрелгән граждан хезмәткәренә язмача хәбәр итә.

22. Министрның язмача ризалыгы белән, Сайтлар турында мәгълүматлар бу хакта бер үк вакытта үзенә карата тикшерү үткәрелгән граждан хезмәткәренә хәбәр итеп, тикшерү үткәрүгә нигез булган мәгълүмат тапшырган хокук саклау органнарына, сәяси партияләрнең һәм закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булып тормаучы башка гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләрнең даими эшләүче җитәкче органнарына, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына, персональ мәгълүматлар һәм дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарын үтәү нигезендә, тапшырылырга мөмкин.

23. Тикшерү материаллары тикшерү тәмамланганнан соң өч ел эчендә кадрлар бүлегендә саклана, шуннан соң архивка тапшырыла.

## IV. Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмаган өчен җаваплылык

24. Гражданин Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмаган очракта граждан хезмәтенә кабул ителә алмый, ә граждан хезмәткәре гражданлык хезмәтендә эшли алмый.

25. Граждан хезмәткәренең Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмавы гражданлык хезмәтеннән җибәрүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының _____ елның ______
340-пр номерлы карары белән расланган
Тәртипнең кушымтасы

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләре «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә һәркем өчен ачык мәгълүматлар һәм аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүмат урнаштырган сайтлар һәм (яисә) сайтлардагы сәхифәләр турында белешмәләрне исәпкә алу
журналы

| № п/п | Форманы бирү/кабул итеп алу датасы | Форманы бирүченең ФИӘИ | Форманы бирүченең вазыйфасы (гражданин биләүгә дәгъва кылган вазыйфа) | Форманы бирүченең имзасы (яки форма почта аша килгәндә документ кергән №) | Форманы кабул итеп алучының ФИӘИ | Форманы кабул итеп алучының имзасы | Тикшерү турында мәгълүмат (боерыкның реквизитлары, тикшерү нәтиҗәсе) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |